ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2020 Балык Бистәсе штп. № 294пи

"2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү" муниципаль программасын раслау турында

Районда иҗтимагый һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итүче патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү, балаларда һәм яшьләрдә гражданлык тәңгәллеген, югары патриотик аң, Ватанга тугрылык, конституцион бурычларны үтәүгә әзерлек, толерантлык, этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр культурасын формалаштыру максатыннан, КАРАР БИРӘМ:

1. «2021-2025 елларга балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» район программасын расларга (алга таба-Программа).

2. Программаның заказчысы – координаторы итеп "ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесен билгеләргә.

3. Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетын формалаштырганда мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм шушы максатларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган акчалар чикләрендә Программаның чараларын гамәлгә ашыруга акча бирүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы Балык_Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның 28 декабрендәге
294пи номерлы карары белән расланган

**"2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү" муниципаль программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | "2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү" муниципаль программасы |
| Основания для разработки программы | Татарстан Республикаксы Министрлар Кабинеты карары 17.03.2011 № 204 |
| Программаның муниципаль заказчысы | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесе |
| Программаны төп эшләүче | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге " муниципаль казна учреждениесе |
| Программаны башкаручылар | "ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе;<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесе; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге " муниципаль казна учреждениесе;<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>Балык Бистәсе районы "Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча);<br>Балык Бистәсе РОСТО (ДОСААФ) автомәктәбе (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>“Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;<br>Балык Бистәсе муниципаль районының "Форпост" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге" муниципаль бюджет учреждениесе;<br>«Авыл офыклары» ("Сельские горизонты") газетасы редакциясе (килешү буенча);<br>Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча);<br>Балык Бистәсе муниципаль районының "Спорт мәктәбе " муниципаль бюджет учреждениесе;<br>Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар |

| | |
|---|---|
| | сәламәтләндерү, белем бирү (профиль) үзәге" муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениясе;<br>Балык Бистәсе муниципаль районының "Дельфин" спорт-сәламәтләндерү комплексы муниципаль бюджет учреждениесе. |
| Программаның максатлары | Районда һәм республикада иҗтимагый һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итә торган патриотик тәрбия системасын үстерү һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларында һәм яшьләрендә патриотик аң, Ватанга тугрылык, конституциячел бурычларны үтәүгә әзерлек, толерантлык, этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр культурасын формалаштыру. |
| Программаның бурычлары | Яшьләр сәясәтенең бер юнәлеше буларак патриотик тәрбия өлкәсендә вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлү системасын үстерү аша ведомствоара хезмәттәшлек моделен булдыру;<br>рухи-әхлакый тәрбия бирү, яшьләрне гражданлык һәм патриотик рухта тәрбияләү, шәхеснең һәрьяклап үсеше өчен шартлар формалаштыру;<br>тәрбия технологияләрен камилләштерү;<br>балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы төрле иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм итү;<br>мәктәптә гражданлык-патриотик тәрбия бирү системасын булдыруны дәвам итү;<br>укучыларга гражданлык-патриотик тәрбия бирү алымнарын һәм ысулларын үстерү;<br>патриотик тәрбия белән шөгыльләнүче яшьләр учреждениеләрен, өстәмә белем бирү учреждениеләрен үстерү һәм модернизацияләү;<br>районның инновацион үсешен тәэмин итү өчен патриотик тәрбия бирүнең оештыру-методик базасын үстерү;<br>патриотик тәрбия буенча белгечләр әзерләү һәм яңадан әзерләү;<br>районның тарихи кыйммәтләре һәм Россия икътисадын, мәдәниятен, сәнгатен үстерүдә тоткан роле, үз халкы өчен горурлык хисен саклап калуда район яшьләренең патриотик хисләрен һәм аңын формалаштыру;<br>иҗтимагый оешмаларны (берләшмәләрне), белем бирү оешмаларын, хезмәт коллективларын патриотик тәрбия бирүдә катнашуга җәлеп итү;<br>белем бирү оешмаларында патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү;<br>дәүләтнең төп рухи нигезе буларак, патриотизмны алга таба үстерү максатыннан, фәнни нигезләнгән, оештыру һәм пропаганда эшчәнлеге алып бару. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2021-2025 еллар. |
| Программаны тормышка ашыруның төп юнәлешләре | Программа чаралары түбәндәге юнәлешләр буенча системалаштырыла:<br>- патриотик тәрбия процессын камилләштерү;<br>- гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү; |

| | |
|---|---|
| | - патриотик тәрбиянең фәнни-теоретик һәм методик нигезләрен үстерү;<br>- яшьләрне патриотик тәрбияләү мәнфәгатьләрендә иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) эшчәнлеген координацияләү;<br>- патриотик тәрбия өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү;<br>-патриотик тәрбиядә Россия, Татарстан Республикасының дәүләт символларын һәм Балык Бистәсе муниципаль районы символларын куллану;<br>-гражданлык-патриотик тәрбия бирү буенча эшнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;<br>-гражданлык-патриотик тәрбия бирүне баету;<br>-уку дисциплиналары курсларында гражданлык-патриотик юнәлешне көчәйтү;<br>-гражданлык-патриотик тәрбиянең методик нигезләрен үстерү:<br>- Ватан патриоты шәхесен формалаштыру һәм үстерү проблемалары буенча методик рекомендацияләр эшләү;<br>-гражданлык-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм гомумиләштерү, аны мәктәпләр эше практикасына кертү;<br>- укучылар гаиләләрендә гражданлык-патриотик тәрбиядә актив катнашуның формаларын үстерү |
| Программаны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләлеге гомумиләштерелгән бәяләү күрсәткечләре сыйфатында чыгыш ясый торган объектив критерийлар системасын куллануга нигезләнә. Алар әхлакый - рухи һәм сан параметрлары белән тәкъдим ителгән.<br>Рухи параметрлар:<br>укучыларның толерантлыгын арттыру, Татарстан, Россия Федерациясе халыкларының бердәмлеген һәм дуслыгын ныгыту;<br>укучыларның гражданлык һәм патриотик бурычларын үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе һәм омтылышы, аларның иҗтимагый һәм шәхси мәнфәгатьләрен яраштыру сәләте һәм теләге, алар тарафыннан Ватанның чәчәк атуы эшенә кертелә торган реаль өлеш;<br>үз Ватаның өчен мәхәббәт һәм горурлык хисе тәрбияләү;<br>үз иленнең гореф-гадәтләренә сакчыл караш тәрбияләү.<br>Сан параметрлары :<br>патриотик юнәлештәге күргәзмәләр;<br>патриотик клублар һәм берләшмәләр эшчәнлеге белән шөгыльләнүче укучылар;<br>патриотик тематика буенча үткәрелгән фестивальләр һәм конкурслар;<br>хәрби-спорт уеннары үткәрү;<br>үткәрелгән фәнни-гамәли конференцияләр;<br>хәрби каберлекләрне эзләү, төзекләндерү эшләре, Бөек Ватан сугышына бәйле урыннарына походлар оештыру;<br>сугыш һәм хезмәт ветераннарына шефлык эше алып бару;<br>Балык Бистәсе муниципаль районында патриотик тәрбия бирүнең гражданин һәм патриотның социаль-актив шәхесен формалаштыру буенча дәүләт һәм иҗтимагый |

| | |
|---|---|
| | институтларның тырышлыгын берләштерергә сәләтле нәтиҗәле системасын алга таба үстерү. |
| Программаны тормышка ашыруга контроль системасы | Әлеге программада катнашучылар Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына хисап тоталар. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге», "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесе Программа чараларын тормышка ашыруны планлаштыру, үзара хезмәттәшлек, координацияләү һәм тикшереп торуны оештыралар. |
| Программаны финанслау чыганаклары | Җирле бюджет (агымдагы финанслау), спонсорлык чаралары һәм башка бюджеттан тыш чыганаклар.<br>Программаны финанслауның гомуми күләме 2919,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җирле бюджет акчалары исәбеннән-2 919,5 мең сум<br>(мең сум)<br><br>еллар / Балык Бистәсе муниципаль районы җирле бюджет акчалары (ҖБ (агымдагы финанслау):<br>2021 – 537,0<br>2022 – 556,0<br>2023 – 579,0<br>2024 – 587,5<br>2025 – 660,0<br>Всего: – 2 919,5<br><br>Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |

| еллар | Балык Бистәсе муниципаль районы җирле бюджет акчалары (ҖБ (агымдагы финанслау) |
|---|---|
| 2021 | 537,0 |
| 2022 | 556,0 |
| 2023 | 579,0 |
| 2024 | 587,5 |
| 2025 | 660,0 |
| Всего: | 2 919,5 |

## I. Программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикасы, шул исәптән программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

Программа Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына, яшүсмерләренә һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү системасының эчтәлеген алга таба да төп үсеш юлларын билгели җәмгыятьнең рухи-әхлакый бердәмлегенең төп нигезе буларак гражданнарның патриотик аңын формалаштыруга юнәлдерелгән.

Программа патриотик тәрбия өлкәсендә төп бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән хокукый, оештыру һәм методик чаралар комплексыннан гыйбарәт.

Программа патриотик тәрбия проблемаларының киң спектрын хәл итүдә муниципаль структуралар һәм иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләрнең уртак эшчәнлеген күз алдында тота һәм алга таба да аңа динамика бирергә бурычлы. Сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре турында кайгырту сүздә түгел, ә чынлыкта булырга тиеш.

Хәрби Көчләр сафына чакырылыш уңышлы үткәрелә, яшүсмерләр армиядә хезмәт итүгә яхшырак әзерләнгән. Районда «Армиягә чакырылучылар көне»традицион рәвештә үткәрелә. Хәрби-спорт уеннары, җыр һәм сафта йөрү парадлары даими уздырыла. Эзтабарлар отрядлары аеруча тантаналы рәвештә Хәтер Маршы, Кар десанты, велоузышлар, экспедицияләр үткәрәләр.

Патриотик тәрбияне алга таба камилләштерү, тәҗрибә туплау максатыннан , Хәтер, Дан , Батырлык дәресләренә методик кулланмалар, мастер-класслар эшләнелә.

Патриотик тәрбия буенча фестивальләр, конференцияләр, слет-конкурслар үткәрү балаларыбызның бу вакыйгаларга, халыкның батырлыкларына карата хисләрен һәм мәнфәгатьләрен чагылдыра. «Авыл офыклары» район газетасында сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәренең батырлыкларын яктырту буенча аерым сәхифә эшләнде.

Яшьләрнең соңгы елларда сайлау кампанияләрендә актив катнашуын да билгеләп үтәргә кирәк. Актив тормыш позициясе һәм бу мөһим вакыйга өчен шәхси җаваплылык хисе участок сайлау комиссияләре эшендә актив катнашкан яшь гражданнарны характерлый..

Җирле үзидарә муниципаль органнарының район яшьләре арасында физик культура, спорт өлкәсендә эшне оештыру буенча эшчәнлеге даими рәвештә активлаша.

Шул ук вакытта патриотик тәрбия системасының нәтиҗәле эшләве өчен барысы да эшләнмәгән әле. Әхлаклылык, гражданлык һәм патриотизм тулы мәгънәсендә җәмгыятьне берләштерүче нигезгә әверелмәде әле. Күп очракта ата-аналар, гаилә, коллектив, җәмгыять, Ватан алдында җаваплылык һәм бурыч хисе югалган. Болар барысы да патриотик тәрбиянең югары рухи-әхлакый принципларны һәм гражданлык җаваплылыгын, үз Ватаныңа мәхәббәт һәм тугрылык, җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә әзерлекне, район үсеше планнарын тормышка ашыруда актив катнашуны тәрбияләүгә юнәлдерелгән программалы методлар белән бөтен комплекс проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшне дәвам итү кирәклеге турында сөйли.

Хәзерге вакытта эшне алга таба камилләштерү, түбәндәгеләргә юнәлдерелгән чаралар үткәрү зарурлыгы туды:

– югары рухи-әхлакый принциплар һәм гражданлык җаваплылыгын, үз ватаныңа мәхәббәт һәм тугрылык, җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә әзерлек тәрбияләү, районның үсеш планнарын тормышка ашыруда актив катнашу;

- мәдәни-тарихи кыйммәтләр нигезендә, яшьләрдә патриотик хис һәм аң формалаштыру;

– Ватаныбызның күп гасырлык тарихын, Россиянең дөнья тарихында тоткан урынын һәм ролен, илнең бәйсезлеге һәм мөстәкыйльлеге өчен көрәшкән төрле буыннарның героик үткәнен өйрәнү;

- конститутцион, гражданлык һәм хәрби бурычны тирәнтен аңлавны формалаштыру, югары культура һәм белемлелекне үстерү;

- Ватанга лаеклы хезмәт итүгә әзер булу идеясын аңлау;

– үз-үзеңне тоту, фидакарьлек, җаваплылык һәм коллективизмның югары әхлаклы, профессиональ-этик нормаларын формалаштыру, хезмәткә хөрмәт һәм намуслы мөнәсәбәт тәрбияләү;

- яшүсмерләр һәм яшьләрнең сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, наркомания, эчкечелек, хокук бозуларны һәм күзәтүсезлекне профилактикалау, яшьләрнең сәламәтлеген яхшырту.

Әлеге программаны тормышка ашыру нәтиҗәле, ведомствоара хезмәттәшлекне тәэмин итәргә мөмкинлек һәм муниципаль районның үсеп килүче буынына патриотик тәрбия бирүдә уңай нәтиҗәләр бирәчәк.

Болар барысы да патриотик тәрбиянең программалы методлар белән барлык проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшне дәвам итү һәм гамәлләрне координацияләү кирәклеге турында сөйли.

## II. Программаның төп максаты, бурычлары, чаралары, аны тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләрен тасвирлау

Программаның төп максаты:

районда һәм республикада иҗтимагый һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итә торган патриотик тәрбия системасын алга таба үстерү һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларында һәм яшьләрендә патриотик аң, Ватанга тугрылык, конституцион бурычларны үтәүгә әзерлек, толерантлык, этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр культурасын формалаштыру.

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

-яшьләр сәясәтенең бер юнәлеше буларак патриотик тәрбия өлкәсендә вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлү системасын үстерү аша ведомствоара хезмәттәшлек моделен булдыру;

-рухи-әхлакый тәрбия бирү, яшьләрне гражданлык һәм патриотик рухта тәрбияләү, шәхеснең һәрьяклап үсеше өчен шартлар формалаштыру;

-тәрбия технологияләрен камилләштерү;

-балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы төрле иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм итү;

-мәктәптә гражданлык-патриотик тәрбия бирү системасын булдыруны дәвам итү;

-укучыларга гражданлык-патриотик тәрбия бирү алымнарын һәм ысулларын үстерү;

-патриотик тәрбия белән шөгыльләнүче яшьләр учреждениеләрен, өстәмә белем бирү учреждениеләрен үстерү һәм модернизацияләү;

-районның инновацион үсешен тәэмин итү өчен патриотик тәрбия бирүнең оештыру-методик базасын үстерү;

-патриотик тәрбия буенча белгечләр әзерләү һәм яңадан әзерләү;

-районның тарихи кыйммәтләре һәм Россия икътисадын, мәдәниятен, сәнгатен үстерүдә тоткан роле, үз халкы өчен горурлык хисен саклап калуда район яшьләренең патриотик хисләрен һәм аңын формалаштыру;

-иҗтимагый оешмаларны (берләшмәләрне), белем бирү оешмаларын, хезмәт коллективларын патриотик тәрбия бирүдә катнашуга җәлеп итү;

-белем бирү оешмаларында патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү;

-дәүләтнең төп рухи нигезе буларак, патриотизмны алга таба үстерү максатыннан, фәнни нигезләнгән, оештыру һәм пропаганда эшчәнлеге алып бару.

Программаны тормышка ашыруның төп юнәлешләре

1) патриотик тәрбия процессын камилләштерү.

Патриотик тәрбия процессын камилләштерү буенча чаралар системасында түбәндәгеләр карала:

яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча эшнең сыйфатын күтәрү;

хәзерге этапта патриотик тәрбия бирү буенча эшнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;

патриотик тәрбия эчтәлеген баету;

Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчылар истәлеген мәңгеләштерү;

җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә, Ватанны саклау буенча бурычларны үтәүгә әзерлек тәрбияләү;

патриотик тәрбия бирү өлкәсендә учреждение һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген һәм координацияләүне тәэмин итү;

патриотик тәрбия процессы белән идарә итү системасын камилләштерү;

патриотик тәрбия буенча тәрбия процессын контрольдә тоту.

Патриотик тәрбия өлкәсендә белгечләр әзерләү системасын камилләштерү;

Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча чаралар системасы тарафыннан түбәндәге чаралар күздә тотыла::

хәрби хезмәтнең абруен күтәрү;

яшьләрне физик һәм психологик яктан әзерләү;

спортның хәрби-гамәли, спорт-техник төрләрен популярлаштыру;

хәрби хезмәткә чакырылучыларның белем дәрәҗәсен күтәрү, алар тарафыннан хәрби-учет белгечлекләрен алу;

гражданнарны хәрби хезмәт нигезләренә өйрәтү.

2) патриотик тәрбиянең фәнни-теоретик һәм методик нигезләрен үстерү.

Патриотик тәрбиянең фәнни-теоретик һәм методик нигезләрен үстерү буенча чаралар системасы белән күздә тотыла:

Балык Бистәсе муниципаль районында патриотик тәрбия бирү буенча методик үзәк төзү;

патриотик тәрбия өлкәсендә уку һәм махсус программалар һәм методикалар комплексын эшләү;

патриотик тәрбия өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм гомумиләштерү, аны патриотик эш практикасына кертү.

3) иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) эшчәнлеген координацияләү.

Патриотик тәрбия мәнфәгатьләрендә иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) эшчәнлеген координацияләү буенча чаралар системасы тарафыннан карала:

- патриотик тәрбия эшендә иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) һәм иҗади берлекләрнең катнашу өчен шартлар тудыру;

-РОСТОның патриотик тәрбия эшен активлаштыру, мәдәният учреждениеләре, иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр), иҗат интеллигенциясе вәкилләренең хәрби-шефлык эшендә катнашуы, хәрби хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе һәм дөнья мәдәнияте байлыкларына җәлеп итүгә юнәлдерелгән хәрби-шефлык эшендә катнашуы;

- район халкының патриотик аңын формалаштыруга иҗтимагый-тәрбия йогынтысының актив формаларын үстерү.

4) патриотик тәрбия өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү.

Патриотик тәрбия өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү буенча чаралар системасында карала:

массакүләм мәгълүмат чараларының патриотизмны пропагандалауда тагын да киңрәк катнашу өчен шартлар тудыру.

5) Россия һәм Татарстан Республикасының дәүләт символларын патриотик тәрбиядә куллану.

Россия һәм Татарстан Республикасының дәүләт символларын патриотик тәрбиядә куллануны регламентлаштыру максатларында карала:

патриотик тәрбия бирүдә Россия һәм Татарстан Республикасының дәүләт символларын куллану буенча кулланмалар, оештыру һәм методик рекомендацияләр бастырып чыгару;

Россия һәм Татарстан Республикасының дәүләт символларын кулланып гражданнарны патриотик тәрбияләү мәсьәләләре буенча район конкурслары, күргәзмәләр һәм экспозицияләр үткәрү;

белем бирү оешмаларында Россия һәм Татарстан Республикасының дәүләт символикасын, дәүләт флагларын, гербларын һәм гимннарын рәсми куллану тәртибен өйрәнүне оештыру.

Программа чаралары исемлеге аңа Кушымтада тәкъдим ителгән.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чаралары җирле бюджет (агымдагы финанслау), спонсорлык чаралары һәм башка бюджеттан тыш чыганаклар хисабына тормышка ашырыла.

Программаны финанслауның гомуми күләме 2919,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җирле бюджет акчалары исәбеннән-2 919,5 мең сум

(мең сум)

| Ел | Балык Бистәсе муниципаль районы җирле бюджет акчалары (ҖБ) (агымдагы финанслау) |
|---|---|
| 2021 | 537,0 |
| 2022 | 556,0 |
| 2023 | 579,0 |
| 2024 | 587,5 |
| 2025 | 660,0 |
| Барлыгы: | 2 919,5 |

Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаның муниципаль заказчысы - координаторы-«ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе.

Программа чараларын тормышка ашыруда катнашалар:

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, «Балык Бистәсе муниципаль районы «Форпост» яшьләр (студентлар) берләшмәләре үзәге" муниципаль бюджет учреждениесе;

Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге (килешү буенча), «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча), Балык Бистәсе районы РОСТО (ДОСААФ) авто мәктәбе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге (килешү буенча), «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча), шулай ук программага кушымтада санап үтелгән башка учреждениеләр һәм оешмалар (килешү буенча).

Программаны тормышка ашыру кысаларында башкаручылар тарафыннан түбәндәге функцияләрне башкару күздә тотыла:

патриотик тәрбия бирү программаларын (планнарын) эшләү һәм аларны гамәлгә ашыруны оештыру (программаны үтәү буенча конкрет эшләр, һәр чара буенча кирәкле чыгымнар һәм аларны финанслау чыганаклары күрсәтелгән);

патриотик тәрбия буенча җирле координацион совет (яки комиссия, штаб) төзү.

Җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә патриотик тәрбия процессын гамәлгә ашыралар, тулаем патриотик тәрбия системасының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен үз көчләрен берләштерәләр.

## V.Программаны икътисади һәм социаль бәяләү нәтиҗәлелеге

Патриотик тәрбия бирү эшенең нәтиҗәлелегенең мөһим шарты булып, гомумиләштерелгән бәяләү күрсәткечләре нигезендә аның торышын даими анализлау тора.

Бу күрсәткечләр тулаем патриотик тәрбиянең торышын гына түгел, ә бу эшнең аерым якларын да билгеләргә мөмкинлек бирә.

Программаны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр

Үсеп килүче буында югары гомуми культура, патриотик хисләр һәм Россия, Татарстан Республикасы, районның тарихи кыйммәтләре нигезендә үзаң формалаштырырга мөмкинлек бирүче патриотик тәрбиянең бердәм системасын булдыру.

Яшь буында Ватанга мәхәббәт, гражданлык бурычларын һәм конституцион бурычларын аңлау тәрбияләү.

Яшүсмерләр клублары, патриотик юнәлештәге кадет сыйныфлары булдыру.

Бала һәм яшүсмернең әхлакый, интеллектуаль һәм физик формалашуы өчен уңай шартлар тудыру.

Яшь буынга патриотик һәм гражданлык тәрбиясе бирүдә район, авылларның гаиләләренә, иҗтимагый оешмаларына адреслы ярдәм күрсәтү.

Толерантлыкны арттыру, җәмгыятьтә идеологик каршылык дәрәҗәсен киметү.

Халыклар бердәмлеген һәм дуслыгын ныгыту.

Гражданнарның икътисад үсешендә кызыксынуларын тәэмин итү, җәмгыятьтә социаль киеренкелекне киметү.

Гражданнарның Ватанны саклауга әзерлегенә карата дөньяви карашын тәрбияләү.

Программаны тормышка ашыруның соңгы нәтиҗәсе буларак районда патриотизм үсешенең уңай динамикасы, гражданнарның, бигрәк тә яшьләрнең социаль һәм хезмәт активлыгы, аларның җәмгыять һәм дәүләт эшчәнлегенең төп өлкәләрен үстерүгә керткән өлешен арттыру, гражданнарның аерым төркемнәренең экстремистлык күренешләрен кисәтү, рухи яңарыш, социаль-икътисади һәм сәяси тотрыклылык һәм милли иминлекне ныгыту күздә тотыла.

"2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү" муниципаль программасына кушымта

**"2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү" муниципаль программасының чаралар исемлеге һәм Программа чаралары буенча финанслау**

| № п\п | Чаралар исемлеге | Үтәү (уздыру) сроклары | Башкаручылар | Чыгымнарны еллар буенча җирле бюджет акчалары хисабына финанслау (агымдагы финанслау), мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Оештыру чаралары | | | | | | | | |
| 1 | Балык Бистәсе муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү буенча ведомствоара комиссия утырышы | Кварталга бер тапкыр | Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча ведомствоара комиссия (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 2 | Яшәү урыны буенча хәрби-патриотик, спорт юнәлешендәге яшүсмерләр клублары челтәрен булдыру, аларны үстерү | 2021-2025 еллар | ЯССТБ МКУ, МБ | - | - | - | - | - |
| 3 | Яшь гражданнарны патриотик тәрбияләүдә катнашучы иҗтимагый берләшмәләр турында мәгълүматлар базасын булдыру һәм системалы яңарту | 2021-2025 еллар | ЯССТБ МКУ, МБ, район ветераннар Советы (килешү буенча), ТР хәрби комиссариаты- | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | | | | | |
| 4 | Хәрби хезмәткә чакырылачак яшьләрне әзерләү программалары нигезендә районның гомуми белем бирү мәктәпләренең, Агротехник техникумның укыту-методик һәм матди-техник базасын ныгыту | даими | МБ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча), «Балык Бистәсе агротехника техникумы» (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 5 | Патриотик тәрбия буенча педагогларны әзерләү дәрәҗәсен күтәрү (курслар, семинарлар, конференцияләр, мастер-класслар) | 2021-2025 еллар | МБ | - | - | - | - | - |
| 6 | "Патриот" яшьләрне спорт-патриотик һәм армиягә кадәр әзерләү республика үзәге базасында белем бирү оешмаларында, берләшмәләрендә патриотик тәрбия оештыручылар өчен квалификация күтәрү курсларында катнашу | 2021-2025 еллар | ЯССТБ МКУ , МБ | - | - | - | - | - |
| Яшь гражданнарны патриотик тәрбияләү өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү | | | | | | | | |
| 7 | Балаларга һәм яшьләргә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү буенча семинарлар оештыру һәм үткәрү | ел саен | МБ, ЯССТБ МКУ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 8 | Геройлар, Бөек Ватан сугышы, тыл хезмәтчәннәре турында китаплар буенча уку | ел саен | МБ, ЯССТБ , ТР хәрби | - | - | - | - | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | конференцияләре үткәрү.ү. Рефератлар һәм иҗади эзләнү-тикшеренү эшләре әзерләү | | комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | | | | | |
| 9 | Хәбәрсез югалган һәм һәлак булган кешеләр турында мәгълүматлар банкын тулыландыру һәм "Хәтер " китабы нәшрияты белән даими элемтә урнаштыру | ел саен | МБ, ЯССТБ МКУ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча), район ветераннар Советы (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 10 | Тарихи-туган якны өйрәнү музейларында, мәгариф музейларында экскурсияләр үткәрү һәм катнашу | ел саен | МБ, СМӨБ | - | - | - | - | - |
| 11 | "Тормыш иминлеге нигезләре" курсы буенча «Татарстан Республикасы ел укытучысы " республика конкурсында катнашу | ежегодно | МБ | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 2,0 |
| 12 | Яшьләрне хәрби белгечлекләр буенча укытуны оештыру | ел саен | ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча), ХМҮ (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| Балалар һәм яшьләр арасында патриотик тәрбия бирү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар, спорт чаралары | | | | | | | | |
| 13 | Көз һәм яз айларында хәрби хезмәткә чакырылучыларның республика | ел саен | ЯССТБ МКУ, МБ, ТР хәрби | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 30,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | спартакиадасын уздыруда катнашу | | комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | | | | | |
| 14 | "Җиңүгә тиңләшү” республика ярышларында катнашу | ел саен | ЯССТБ МКУ , МБ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | 20,0 | 22,0 | 23,0 | 24,0 | 30,0 |
| 15 | “Мин-Россия гражданины " паспортлар тапшыру буенча яшьләр патриотик акциясе | ел саен | ЯССТБ МКУ, МБ, ЗАГС бүлеге, РФ ЭЭМ бүлеге (килешү буенча) | 12,0 | 12,0 | 12,0 | 12,0 | 15,0 |
| 16 | Балык Бистәсе муниципаль районы хәрби хезмәткә алынучылар арасында хәрби-гамәли спорт төрләре буенча район, зона ярышларында катнашу һәм уздыру | апрель, октябрь 2021-2025 еллар | ЯССТБ МКУ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | 24,0 | 24,0 | 24,0 | 24,0 | 30,0 |
| 17 | Хәрби-патриотик тәрбия буенча ярышлар | февраль-март 2021-2025 еллар | ЯССТБ МКУ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 20,0 |
| 18 | Хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү | апрель, октябрь 2021-2025 | ЯССТБ МК , ТР хәрби комиссариаты- | 50,0 | 55,0 | 55,0 | 60,0 | 65,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | еллар | нының Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | | | | | |
| 19 | Спортның техник төрләрен үстерү (картинг, хәрби-гамәли төрләре) | 2021-2025 еллар | ЯССТБ МКУ , МБ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча), РОСТО (ДОСААФ) (килешү буенча) | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 40,0 |
| 20 | Җиңү көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү | май 2021-2025 еллар | ИК МР, МБ , ЯССТБ МКУ , СМӨБ, МБУ «Форпост», программа чараларын башка башкаручылар (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 21 | Хәрби-патриотик юнәлешкә багышланган мәктәп басмалары, балалар рәсемнәре, иншалары конкурслары үткәрү | 2021-2025 еллар | МБ | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 15,0 |
| 22 | Проведение уроков мужества, организация встреч ветеранов Великой Отечественной войны, локальных войн, ветеранов тыла в учебных заведениях района, посвященных дням воинской славы (Победным дням) России<br>район уку йортларында хәрби дан көннәренә багышланган (Җиңү көннәренә) батырлык дәресләре үткәрү, Бөек Ватан сугышы, локаль сугыш, тыл ветераннары белән | ел саен | ЯССТБ МКУ , МБ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | 18,0 | 18,0 | 18,0 | 18,0 | 20,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | очрашулар оештыру. | | | | | | | |
| 23 | Хәрби дан һәйкәлләрен һәм мемориалларын карап тору | ел саен | МБ, СМӨБ , ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча), район ветераннар Советы (килешү буенча), җирлек-ләр БК (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 24 | Республиканың иң яхшы музейларын Бөтенроссия конкурсына тәкъдим итү өчен иң яхшы музей, хәрби дан почмагы республика конкурсында катнашу һәм үткәрү | ел саен | МБ, «Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музее» | - | - | - | - | - |
| 25 | "Аҗаган " хәрби-патриотик уенын үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ , СМӨБ, МБ , ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 26 | “Җиңү "республика хәрби-спорт уенында катнашу | | ЯССТБ МКУ , МБ | - | - | - | - | - |
| 27 | Балалар һәм яшьләр өчен «Алга, яшь армиячеләр!" спорт-патриотик уенында катнашу | март-апрель 2021-2025 еллар | ЯССТБ МКУ, МБ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү | 7,0 | 7,5 | 8,0 | 8,5 | 10,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | буенча) | | | | | |
| 28 | Россия һәм Татарстанның дәүләт символикасын иң яхшы белүгә укучыларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсында катнашу | ноябрь-декабрь 2021-2025 еллар | МБ , ЯССТБ | - | - | - | - | - |
| 29 | Хәрби-патриотик җырлар район смотр-конкурсы.<br>“Без Данлы Җиңүне хәтерлибез" әдәби-музыкаль композициясе | ел саен | СМӨБ , МБ | 20,0 | 21,0 | 22,0 | 24,0 | 25,0 |
| 30 | Патриотик тәрбия буенча китап күргәзмәләрен, тематик җыентыкларны, уку конференцияләрен оештыру, социаль роликлар чыгару | ел саен | МБ, СМӨБ, «Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музее» | 5,0 | 5,5 | 6,0 | 6,0 | 8,0 |
| 31 | "Созвездие-Йолдызлык», «Ватаным" республика конкурсларында катнашу | ел саен | ЯССТБ МКУ , СМӨБ , МБ | 300,0 | 310,0 | 320,0 | 330,0 | 350,0 |
| 32 | Патриотик эчтәлектәге кино-һәм видеофильмнар күрсәтү | ел саен | МБУ «Киноучрежде-ние» | - | - | - | - | - |
| 33 | Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм инвалидларына ярдәм итү өчен волонтер отрядларының һәм инициатив төркемнәрнең шефлык эшен оештыру | 2021-2025 еллар | МБ | - | - | - | - | - |
| 34 | Армиягә чакырылуга кадәрге яшьләргә медицина тикшерүләрен уздыру | 1 квартал 2021-2025 еллар | ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча), “Балык Бистәсе ҮРБ” (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 35 | Якташларыбызның хәрби һәм хезмәт батырлыклары турында материалларны өйрәнү һәм җыю эшен оештыру | ел саен | СМӨБ , МБ, «Балык Бистәсе туган якны | - | - | 10,0 | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | өйрәнү музее» | | | | | |
| 36 | 10 сыйныф укучылары белән биш көнлек уку җыеннары үткәрү | ел саен | МБ, ТР хәрби комиссариаты-ның Балык Бистәсе районы бүлеге (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| 37 | Бөек Ватан сугышы ветераннары, әфганчылар белән очрашулар оештыру | ел саен | МБ, ЯССТБ МКУ | - | - | - | - | - |
| 38 | "Форпост" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре район һәм республика конкурсларында катнашу һәм үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ , МБУ «Форпост» | - | - | - | - | - |
| Патриотик тәрбия мәсьәләләре буенча гражданнарның иҗтимагый фикерен формалаштыру | | | | | | | | |
| 39 | Уку йортларында, предприятиеләрдә, җәмәгать урыннарында патриотик юнәлештәге күрсәтмә агитация стендлары урнаштыру | ел саен | ЯССТБ МКУ , СМӨБ , МБ | - | - | - | - | - |
| 40 | Район газетасы битләрендә балаларга һәм яшьләргә патриотик һәм әхлакый тәрбия бирү буенча рубрика булдыру | даими | “Авыл офыклары” газетасы редакциясе (килешү буенча) | - | - | - | - | - |
| Барлыгы: | | | | 537,0 | 556,0 | 579,0 | 587,5 | 660,0 |
| Программа буенча барлыгы: **2919,5** | | | | | | | | |

*Кулланылган кыскартулар исемлеге:

МР БК - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты;

ЯССТБ МКУ- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;

МБ - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;

СМӨБ - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль- мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;

“Балык Бистәсе ҮРБ” - “Балык Бистәсе үзәк район больницасы” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

“БЯСМ” МБУ- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе” муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениясе;

БСББҮ- "Балык Бистәсе муниципаль районы балалар сәламәтләндерү, белем бирү (профиль) үзәге" муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе;

"Дельфин" СОК "МБУ-Балык Бистәсе муниципаль районы «Дельфин «спорт-сәламәтләндерү комплексы" муниципаль бюджет учреждениесе;

ФОРПОСТ – Балык Бистәсе муниципаль районының “ФОРПОСТ” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәпләр) берләшмәләре үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе;

ҖБ- җирле бюджет;

“Авыл офыклары” газетасы редакциясе- “Татмедиа” АҖ филиалы “Авыл офыклары” (“Сельские горизонты”) Балык Бистәсе муниципаль районы газетасы;

Җирлекләр БК- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керә торган авыл җирлеге башкарма комитетлары;

РФ ЭЭМ бүлеге - Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге;

«Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музее» МБУ-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе;

«Киноучреждение» МБУ – муниципальное бюджетное учреждение «Киноучреждение Рыбно-Слободского муниципального района РТ»;

«Балык Бистәсе агротехника техникумы» ДАҺБУ - “Балык Бистәсе агротехника техникумы” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

ХМҮ – “Балык Бистәсе районы халык мәшгульлеге үзәге” дәүләт казна учреждениесе;